# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Хәсәншәех авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

**“18” ноябрь 2022 ел** **№ 6**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2022 елның 18 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены беркетмәсе төзелде:

«2023 елда Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Хәсәншәех авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, түләү күләме 200 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, 70 яшьтән узган гражданнардан тыш, түләү күләме 400 сум тәшкил иткән үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (контракт буенча хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгән, үз ихтыяры белән махсус хәрби операциядә катнашкан затларны) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

- авылны төзекләндерү өчен җиһазлар сатып алу (бензин чапкычы - 1 данә, бензин чапкычына запас частьләр);
- 1 данә күләмендә янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру;
- Хәсәншәех авылында су челтәрләрен ремонтлау;
- урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру;
- Хәсәншәех авылының Комсомол урамыннан “Киндер күле” чишмәсенә кадәрге җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлын вак таш җәеп тигезләү;
- МТЗ 80 тракторына асылмалы җиһазлар сатып алу (чапкыч);
- Хәсәншәех авылында юл кырыйларын, авышлыкларны грейдер белән тигезләү, урам-юл челтәренең юл өслегеннән пычракны җыештыру?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ””

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучы сайлау хокукына ия затлар исемлегенә 438 граждан, тавыш бирүдә катнашкан 240 кеше кертелде.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашучы 240 кеше тавыш бирде; “Каршы" позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Хәсәншәех торак пунктында халык җыены узды, җыен нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2. «2023 елда Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Хәсәншәех авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, түләү күләме 200 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, 70 яшьтән узган гражданнардан тыш, түләү күләме 400 сум тәшкил иткән үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (контракт буенча хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгән, үз ихтыяры белән махсус хәрби операциядә катнашкан затларны) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

- авылны төзекләндерү өчен җиһазлар сатып алу (бензин чапкычы - 1 данә, бензин чапкычына запас частьләр);
- 1 данә күләмендә янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру;
- Хәсәншәех авылында су челтәрләрен ремонтлау;
- урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру;
- Хәсәншәех авылының Комсомол урамыннан “Киндер күле” чишмәсенә кадәрге җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлын вак таш җәеп тигезләү;
- МТЗ 80 тракторына асылмалы җиһазлар сатып алу (чапкыч);
- Хәсәншәех авылында юл кырыйларын, авышлыкларны грейдер белән тигезләү, урам-юл челтәренең юл өслегеннән пычракны җыештыру?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ””

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны кабул ителгән көннән 7 көн эчендә, ТР, Арча районы, Хәсәншәех авылы, Космонавтлар урамы, 20 йорт, Татарстан урамы, 42 йорт, Комсомол урамы 31 йорт адреслары буенча мәгълүмат стендларында, Арча муниципаль районының (http://arsk.tatarstan.ru) рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү Татарстан Республикасы Арча

муниципаль районы Апаз авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Апаз авыл җирлеге башлыгы Р.Ф.Котдусов